# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге составына керүче “Мамадыш” совхозының 2 нче фермасы поселогында 2026 елга үзара салым кертү турында

№ 6 28.10.2025 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы матдәләре , «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче матдәсе, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 матдәсе нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең “Мамадыш” совхозының 2 нче фермасы поселогында узган гражданнар җыены
КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең “Мамадыш” совхозының 2 нче фермасы поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, 1,2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, күп балалы гаиләләрдән, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары кала, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын урнаштыру, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (мәйданчык урнаштыру);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту: (урам юлларын кардан чистарту һәм юлларны тигезләү);
- электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка билгеләнгән җайланмаларны ремонтлау: (агымдагы ремонт, урам утлары лампаларын сатып алу һәм алыштыру)

3.Әлеге карарны Кызыл Тау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнарҗыенындарәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе В.А. Гиззатуллина